ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2020 Казан ш. № 407-67/тэ-2020

«ТеплоЭнергоСнабжение» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче, җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 27.11.2019 № 5-71/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга ел өчен үзгәрешләр кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм 2021-2022 елларга җылылык энергиясе югалуны компенсацияләү максатында җылылык энергиясе сатып ала торган җылылык челтәрләре оешмаларына, җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) 2021-2020 елларга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, озак сроклы тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ТеплоЭнергоСнабжение» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан

җылылык белән тәэмин итүче, җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2020-2022 елларга тарифлар билгеләү турында» 27.11.2019 № 5-71/тэ карары кушымтасына, аны яңа редакциядә биреп (кушымтада бирелә), үзгәреш кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
27.11.2019 № 5-71/тэ
карарына кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2020 № 407-67/тэ-2020
карары редакциясендә)

«ТеплоЭнергоСнабжение» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятеннән җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга, җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максатында җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2020-2022 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 $кг/см^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 $кг/см^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 $кг/см^2$ кадәр | 13,0 $кг/см^2$ югары | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1 | «ТеплоЭнергоСнабжение» ҖЧҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1290,49 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1322,29 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1322,29 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1368,32 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1368,32 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1491,52 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге